РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ул.Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин ур.,14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50, 7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru кат adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

"04" октябрь 2022 ел №31

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.Ә. Габдрахманов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта
____.________.20______№

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы«Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 31 мартка кәдәр, 18 яшькә җиткән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) тавыш биргәндә катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш башкарыла.

3. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) 2 группа инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар,

в) күпбалалы гаиләләр,

түләү күләме җирле референдум карарында (гражданнар җыенында) билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) блогы җирлек сайтының http://aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук язуга яисә почта элемтәсе аша юлламага тапшыру юлы белән (әлеге Тәртипкә кушымта) бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнарның түләүләрен түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисапны тормышка ашырырга хокуклы оешмалар аша, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмаларын) гамәлгә ашыруга, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша түбәндәге ссылка буенча башкарыла: https://uslugi.tatarstan.ru/.

7. Түләү фактын раслау - приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә кушымта

ИЗВЕЩЕНИЕ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләү турында

түләүченең Ф.И.О. ____________________________________________________________________________

Адрес: _______________________________________________________
__________________________________________________нигезендә
Сезгә бер тапкыр бирелә торган түләү вакыты җиткәнче түләргә кирәк ___________________________
чараларны гамәлгә ашыру ____________________________________________ сум күләмендә,
түбәндәге реквизитлар буенча:_________________________________________________________
Алучының банкы БИК ___________________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучы Сч. № __________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК ________________ ОКАТО __________________
Түләү билгеләмәсе _____________________________________________________________________

Җитәкче ________________ _________________________________________
М.П. (имза) (имза расшифровкасы) ,

**кисү линиясе**- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Извещение (хәбәрнамә) № _________________
үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган акчаны бюджетка түләү турында _______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
суммада _________________ сум
Түләүче Ф.И.О ___________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________
Алдым "__" _________________ 20___ ел______________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әлеге хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, извещение тутырыла һәм башкарма комитетта кала.*